ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.04.2021 №550

Торак урын мәйданының хисап
нормасы һәм социаль наем шартнамәсе
буенча торак урын мәйданын бирү
нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьялары нигезендә, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1 Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 18 кв.метрдан да ким булмаган күләмдә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга торак урыны гомуми мәйданының 18 кв. метры күләмендә билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак урыннары биргәндә һәм исәпкә куйганда мәйдан нормалары, гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясе нормативын исәпләү методикасы турында» 2008 елның 5 июнендәге 247 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов